| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 02 » сентябрь 2017ел. № 368-п

**«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 16 августындагы 367-п номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирүнең (балалар бакчаларының) төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына балаларны исәпкә алу һәм алу турында» муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында (алга таба текст буенча-Административ регламент)»**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2017 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 273-ФЭ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 28 декабрендәге 1527 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 9 июнендәге 1049/17 номерлы боерыгы, “Буа муниципаль районы” 44 нче Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.7 пунктка түбәндәге редакциядә 5 абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең Оешмага чираттан тыш укырга хокукы булган очракта, мөрәҗәгать итүчегә «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУга ташламаны раслый торган документларны, шулай ук аларның күчермәләрен тапшырырга кирәк;

2) 3.7.1 пунктчасын 2 абзац түбәндәге редакциядә өстәргә:

«Баланы бер оешмадан икенчесенә күчергәндә гражданнарның ташламалы категориясендәге балалар федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән ташламалардан файдалана».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

3. Карар имзаланган вакыттан үз көченә керә.

Буа муниципаль районы башкарма
комитеты җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы С.Ф. Даутов